| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.02.2022 № 17-П

г. Казань

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Көнчыгыш клубы бинасы (сәүдәгәрләр җыены), (Татар мәдәнияте йортында Горький А.М. чыгыш ясаган бина (1923 ел))», XIX гасыр ахыры, 1923 ел, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектының чикләрен һәм файдалану режимын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен махсус җайга салуның шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак саклау һәм дәүләт саклавы максатларында боерам:

1. 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Көнчыгыш клубы бинасы (сәүдәгәрләр җыены), (Татар мәдәнияте йортында Горький А.М. чыгыш ясаган бина (1923 ел))», XIX гасыр ахыры, 1923 ел, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектының чикләрен һәм территориядән файдалану режимын расларга.
2. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни
мирас объектларын
саклау комитетының 10.02.2022 дәге
17-П номерлы боерыгына
1 кушымта

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Көнчыгыш клубы бинасы (сәүдәгәрләр җыены), (Татар мәдәнияте йортында Горький А.М. чыгыш ясаган бина (1923 ел))», XIX гасыр ахыры, 1923 ел, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектының **территориясе чикләре**

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Көнчыгыш клубы бинасы (сәүдәгәрләр җыены), (Татар мәдәнияте йортында Горький А.М. чыгыш ясаган бина (1923 ел))», XIX гасыр ахыры, 1923 ел, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең картасы (схемасы)

ул. Островского, д.10




**Шартлы билгеләр:**

| | |
|---|---|
| | -мәдәни мирас объекты территориясенең чикләре |
| | -мәдәни мирас объекты |
| | -җир кишәрлеге чикләре |
| **16:50:010210:3** | - кадастр кварталаы имзасы |
| 16:50:010210 | -җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| 1 | -территория чикләренең характерлы ноктасы |

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Көнчыгыш клубы бинасы (сәүдәгәрләр җыены), (Татар мәдәнияте йортында Горький А.М. чыгыш ясаган бина (1923 ел))», XIX гасыр ахыры, 1923 ел, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең картографик тасвирламасы

Төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чиге түбәндәгечә уза:

| Чикне үтү | | Чикне үтү тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | 2 | Төньяк-көнчыгыш өлеш: Кави Нәҗми урамы белән Островский урамы буйлап көньяк-көнчыгыш юнәлештә, кызыл сызык буенча, җир кишәрлегенең алгы чиге буйлап |
| 2 | 3 | Ишегалды территориясе эчендә көньяк-көнбатыш юнәлештә, Островский урамы, бина почмагына кадәр перпендикуляр рәвештә |
| 3 | 4 | Ишегалды территориясе эчендә төньяк-көнбатыш юнәлештә, бина почмагына кадәр |
| 4 | 5 | Ишегалды территориясе эчендә көньяк-көнбатыш юнәлештә, бина почмагына кадәр |
| 5 | 6 | Ишегалды территориясе эчендә төньяк-көнбатыш юнәлештә Кави Нәҗми урамына кадәр |
| 6 | 1 | Төньяк-көнбатыш өлеше: Кави Нәҗми урамы буенча Островский урамы белән кисешкәнгә кадәр, җир кишәрлегенең алгы чиге буйлап |

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Көнчыгыш клубы бинасы (сәүдәгәрләр җыены), (Татар мәдәнияте йортында Горький А.М. чыгыш ясаган бина (1923 ел))», XIX гасыр ахыры, 1923 ел, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең борылыш нокталары таблицасы

| Нокта № | Ноктаның координаталар системасындагы координаталары (МСК-16) | |
|---|---|---|
| | **X** | **Y** |
| 1 | 475809.41 | 1305098.47 |
| 2 | 475774.63 | 1305138.60 |
| 3 | 475763.76 | 1305129.11 |
| 4 | 475776.99 | 1305113.93 |
| 5 | 475770.24 | 1305108.06 |
| 6 | 475789.88 | 1305083.57 |
| 1 | 475809.41 | 1305098.47 |

Татарстан Республикасы мәдәни
мирас объектларын
саклау комитетының 10.02.2022
дәге 17-П номерлы боерыгына
2 кушымта

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Көнчыгыш клубы бинасы (сәүдәгәрләр җыены), (Татар мәдәнияте йортында Горький А.М. чыгыш ясаган бина (1923 ел))», XIX гасыр ахыры, 1923 ел, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясеннән

**файдалану режимы**

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Көнчыгыш клубы бинасы (сәүдәгәрләр җыены), (Татар мәдәнияте йортында Горький А.М. чыгыш ясаган бина (1923 ел))», XIX гасыр ахыры, 1923 ел, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр **рөхсәт ителә:**

- мәдәни мирас объектының физик сакланышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкару, шул исәптән консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү, заманча файдалануга яраклаштыру;
- мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килмәгән һәм мәдәни мирас объектының заманча шартларда эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару;
- мәдәни мирас объектын, аның үзенчәлекләрен үзгәртмичә, функциональ файдалану төрләре нигезендә, саклау предметын тәшкил итүче, шул исәптән әлеге боерык белән билгеләнгән җир кишәрлеген файдалануның төрләрен исәпкә алып, заманча файдалану өчен куллану (рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары Росреестрның 2020 елның 10 октябрендәге ПАМ 12 номерлы «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» боерыгы нигезендә күрсәтелгән):государственное управление (код 3.8.1);

мәгариф һәм агарту (код 3.5)

җәмәгать туклануы (код 4.6.)

тарихи (код 9.3);

- мәдәни мирас объектының югалган элементларын һәм өлешләрен гамәлдәге сызымнар, обмерлар һәм тарихи аналоглар буенча торгызу;
- «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, мәдәни мирас объектының бөтенлеген боза торган корылмаларны һәм объектларын, шул исәптән вакытлы объектларны сүтү;
- гамәлдәге инженерлык инфраструктурасы объектларын (тышкы су белән тәэмин итү, канализация, җылылык белән тәэмин итү, газ, электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру һ.б.) капиталь ремонтлау, шулай ук башкарыла торган эшләр (шул исәптән динамик йогынты) мәдәни мирас объектына йогынты ясамау шарты белән инженерлык инфраструктурасының яңа объектларын җир асты юлы белән салу;
- мәдәни мирас объектын саклап калуга, алардан файдалануга һәм аларны популярлаштыруга юнәлтелгән территорияне төзекләндерү;

- мәйданчыкларда традицион материалларны (кирпеч, таш, гранит һәм башка табигый материалларны, шулай ук табигый материалларны) куллану;

- тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирә торган аерым урнаштырылган яктырту җиһазларын куллану;

- яшелләндерү: агачларны яшелләндерү, агачларны санитар кисү, яшелләндерүнең яңа элементларын утырту;

- тарихи-шәһәр төзелеше мохитен саклап калу, мемориаль һәм архитектура-ансамбль мөнәсәбәтендә югалган тарихи элементларны (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, аларны торгызу өчен кирәкле җитәрлек фәнни мәгълүматлар булган очракта биналарны, корылмаларны, кече архитектура рәвешләрен, коймаларны) торгызу;

- мәдәни мирас объектының төп фасадында мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру беренче каттан да югары түгел;

- кулланучылар игътибарына «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 07 февралендәге 2300-1 номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү өчен билгеләнгән тышкы мәгълүмат чараларын (вывескаларны) урнаштыру: эшчәнлек профиле, оешманың фирма исеме, аның урнашкан урыны (адресы) һәм эш режимы, индивидуаль эшкуарны дәүләт теркәве турында һәм аны теркәгән органның исеме турындагы мәгълүмат законнар нигезендә;

- тышкы мәгълүмат чаралары (вывескалар) биеклеге фриз биеклегеннән 2/3 артык булмаска тиеш, катлар тәрәзәләре арасына теге яки бу корылманы урнаштыру регламентлаштырыла.

Югарыда атап үтелгән барлык эшләр «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә башкарыла.

- Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Көнчыгыш клубы бинасы (сәүдәгәрләр җыены), (Татар мәдәнияте йортында Горький А.М. чыгыш ясаган бина (1923 ел))», XIX гасыр ахыры, 1923 ел, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр **тыела:**

- мәдәни мирас объектын яисә аның аерым элементларын саклап калу, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше мохитен саклау эшләреннән тыш, җир, төзелеш, мелиоратив һәм башка эшләр башкару;

- капиталь төзелеш объектларын төзү һәм капиталь төзелеш объектларының һәйкәл яисә ансамбль территориясендә булган күләм-пространство характеристикаларын арттыру; мәдәни мирас объектын яисә аның аерым элементларын саклау, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше яисә табигый мохитен саклау эшләреннән тыш, җир, төзелеш, мелиоратив һәм башка эшләр башкару;

- тышкы реклама чараларын урнаштыру;

- җир өсте ысулы белән инженерлык инфраструктурасы объектларын (тышкы су белән тәэмин итү, канализация, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру һ.б.) үткәрү;

- киосклар, павильоннар, лапаслар, кече архитектур формалар урнаштыру, югалганнарны торгызудан тыш;

- динамик йөкләнеш тудыручы технологияләрне (бәрмәле машиналардан куллану, кривошипно-шатунлы механизмнар, чүкечләр һәм бәрмә хәрәкәтнең башка механизмнарын куллану, мәдәни мирас объектына һәм аның әйләнә-тирәсендәге төзелешләргә күпсанлы машиналарны берьюлы куллану;

- мәдәни мирас объекты территориясен теләсә кайсы төрдәге һәм формадагы төзелеш, көнкүреш калдыклары белән чүпләү;

- агачларны кисү, санитар кисүләрдән тыш.